ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 декабря 2025г. № 10213

Башкарма комитетның «2025-2027 елларга гражданнар оборонасы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау системасын камилләштерү һәм су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2024 елның 28 октябрендәге 7086 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2025-2027 елларга гражданнар оборонасы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау системасын камилләштерү һәм су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2024 елның 28 октябрендәге 7086 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2025 елның 7 маендагы 3317 номерлы, 2025 елның 22 августындагы 6174 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программа чараларын финанслауны «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетында «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13, «Халыкны һәм территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгы» 03.10, «Су хуҗалыгы» 04.06 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына 2025 елда – 3 343,10 мең сум, 2026 елда – 3 110,00 мең сум, 2027 елда – 3 110,00 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) «2025-2027 елларга гражданнар оборонасы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау системасын камилләштерү һәм су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итү» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2025 | 2026 | 2027 | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 3 343,10 | 3 110,00 | 3 110,00 | 9 563,10 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 3 343,10 | 3 110,00 | 3 110,00 | 9 563,10»; |

- 3 бүлектә «Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау» таблицасын кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

- 6 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен 9 563,10 мең сум күләмендә шәһәр бюджеты акчалары тәшкил итә, шул исәптән:

2025 ел – 3 343,10 мең сум;

2026 ел – 3 110,00 мең сум;

2027 ел – 3 110,00 мең сум.

Программаны тормышка ашыруга ассигнованиеләр кимегәндә яки арткандa, программаны башкаручы чаралар исемлегенә төзәтмәләр кертү буенча тәкъдимнәр кертә.

Программаны финанслау күләмнәре прогноз характерына ия һәм билгеләнгән тәртиптә аңа төгәллекләр кертелергә тиеш.».

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.Ә. Сәлимхановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 5 декабрендәге
10213 номерлы карарына
кушымта

Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау

| Чараларның исеме | | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Индикаторларның зурлыгы | | | | Чыганакны күрсәтеп, финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2024 ел (база) | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Максат: Яр Чаллы шәһәре халкының, территорияләренең һәм инфраструктура объектларының табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән сакланышын күтәрү, аларның тискәре нәтиҗәләрен йомшарту, гражданнар оборонасы өлкәсендәге чараларны тормышка ашыру һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү | | | | | | | | | | | |
| | | | | Кешеләр үлеме белән бәйле табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрнең саны, берәмлек | 0 | 0 | 0 | 0 | Муниципаль бюджет | | |
| Бурыч: гражданнар оборонасы, халыкны һәм шәһәр округы территорияләрен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча чаралар оештыру һәм гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | | |
| 1. | Гражданнар оборонасының иң яхшы саклагыч корылмасына смотр-конкурс үткәрү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | июнь – сентябрь ел саен | оешмаларның катнашучылар саны | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | Икътисад объектларының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча иң яхшы укыту-матди базасына смотр-конкурс үткәрү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | июнь ел саен | оешмаларның катнашучылар саны | 9 | 9 | 9 | 9 | финанслау таләп ителми |
| 3. | Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Яр Чаллы шәһәренең төп чаралар планын эшләү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | декабрь ел саен | эшләнгән документ саны | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми |
| 4. | Шәһәрнең идарә компанияләре карамагында оештырылган гражданнар оборонасы буенча иң яхшы укыту-консультация пунктларына смотр-конкурс үткәрү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | сентябрь ел саен | оешмалар саны, берәмлек | 11 | 13 | 15 | 17 | финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Белем бирү оешмаларының шәхси саклану чаралары белән җиһазланышын контрольдә тоту | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | ел дәвамында | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| 6. | Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының шәхси саклану чаралары белән җиһазланышын контрольдә тоту | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | ел дәвамында | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| 7. | Хисап елы өчен гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә бурычларның үтәлешенә йомгак ясау | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | ел дәвамында | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 8. | Белем бирү оешмаларында «Судагы куркынычсызлык» темасына сыйныф сәгатьләре үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | уку елы дәвамында | катнашкан балалар саны, берәмлек | 68160 | 68170 | 68180 | 68190 | финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9. | Язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча чаралар планын эшләү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | апрель ел саен | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| 10. | Коткаручыларны укытуны оештыру | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | май ел саен | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| 11. | Халыкның күпләп ял итүе өчен оештырылган урыннарда җәмәгать коткару постлары булдыру, җиһазландыру һәм аларның эшен оештыру | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | ел дәвамында | коткару постларының персонал һәм кирәкле җиһазлар белән комплеклаштырылуы, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 3 333,10 | 3 110,00 | 3 110,00 |
| | | | | су объектларында бәхетсезлек очракларының саны, берәмлек | 3 | 0 | 0 | 0 | | | |
| 12. | Пляжларның хуҗалары һәм арендаторлары (судан файдаланучылар) һәм гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгы | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | май ел саен | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | буенча комиссия белән «Җәйге чорда су коену һәм халыкның массакүләм ял итү урыннары әзерлеге турында» темасына киңәйтелгән утырыш үткәрүне оештыру | | | | | | | | | | |
| | Барлыгы: | | | | | | | | 3 340,10 | 3 110,00 | 3 110,00 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева